КАБИНЕТ МИНИСТРОВ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2023 ел, 22 май г.Казань № 620

Татарстан Республикасы дәүләт ихтыяҗлары өчен җир кишәрлеген алу турында

Татарстан Республикасының Спас муниципаль районында «Ким - Кузнечиха - Урман Хмелевкасы» - Фадеевка төбәк әһәмиятендәге автомобиль юлын реконструкцияләү максатларында, Россия Федерациясе Җир кодексының VII бүлегендәге 49 статьясы, VII$^1$ бүлеге, Россия Федерациясе Граждан кодексының 279 һәм 281 статьялары, Татарстан Республикасы Җир кодексының 3 статьясы, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасының территориаль планлаштыру схемасын раслау турында» 2011 ел, 21 февраль, 134 нче карары белән расланган Татарстан Республикасының территориаль планлаштыру схемасы нигезендә Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

1. Татарстан Республикасы Җир һәм мөлкәт мөнәсәбәтләре министрлыгының, «Татарстан Республикасы Транспорт һәм юл хуҗалыгы министрлыгы каршындагы Татарстанның юл-транспорт комплексын карап тоту һәм үстерү баш идарәсе» дәүләт казна учреждениесенең (алга таба – Татарстанның юл-транспорт идарәсе) Татарстан Республикасы Спас муниципаль районында «Ким - Кузнечиха - Урман Хмелевкасы» - Фадеевка төбәк әһәмиятендәге автомобиль юлын реконструкцияләү максатларында Татарстан Республикасы дәүләт ихтыяҗлары өчен Татарстан Республикасы, Спас муниципаль районы, Урта Йорткүл авыл җирлеге адресы буенча урнашкан авыл хуҗалыгы билгеләнешендәге җирләр категориясендәге 4 748 806 кв.метр мәйданлы һәм 16:37:180401:6 кадастр номерлы җир кишәрлегеннән барлыкка килә торган, дәүләт милкендә булган һәм «Хузангаевское» җаваплылыгы чикләнгән җәмгыятенә (алга таба – арендага алучы) арендага тапшырылган 29 кв.метр мәйданлы җир кишәрлеген (алга таба – алына торган җир кишәрлеге) алу турындагы тәкъдимен кабул итәргә.

2. Алына торган җир кишәрлегендә урнашкан 16:37:000000:655 кадастр номерлы «Су белән тәэмин итүнең тышкы челтәрләре» күчемсез мөлкәт объекты алынмаска тиеш дип билгеләргә.

3. Татарстан Республикасы Җир һәм мөлкәт мөнәсәбәтләре министрлыгына түбәндәгеләрне законнар белән билгеләнгән тәртиптә тәэмин итәргә:

10 көн эчендә:

бу карарны үзенең «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге рәсми сайтында урнаштыруны;

бу карарны Татарстан Республикасы Спас муниципаль районындагы Урта Йорткүл авыл җирлегенең муниципаль хокукый актларын рәсми бастырып чыгару (халыкка белдерү) өчен билгеләнгән тәртиптә бастырып чыгаруны;

бу карарның күчермәсен арендаторга, «Роскадастр» гавами-хокукый компаниясенең Татарстан Республикасы буенча филиалына, Татарстанның юл-транспорт идарәсенә җибәрүне;

алына торган җир кишәрлеге өчен түләү күләме билгеләнгәннән соң 30 көн эчендә, Татарстанның юл-транспорт идарәсе белән берлектә, алына торган җир кишәрлегенә аренда шартнамәсе туктатылу турында килешү (алга таба – килешү) әзерләүне һәм аны арендага алучыга җибәрүне;

килешү төзүне;

алына торган җир кишәрлеге арендасы хокукы туктатылган өчен арендага алучыга акча түләүне;

арендага алучы тарафыннан имза куелган килешү законнар белән билгеләнгән срокта тапшырылмаган очракта, судка тиешле дәгъвалар бирүне.

4. Татарстанның юл-транспорт идарәсенә Татарстан Республикасы Спас муниципаль районы башкарма комитетының «Татарстан Республикасының Спас муниципаль районында «Ким - Кузнечиха - Урман Хмелевкасы» - Фадеевка автомобиль юлын реконструкцияләү» объекты территориясен планировкалау проектын һәм межалау проектын раслау турында» 2018 елның 23 маендагы 324 номерлы карары белән расланган территорияне планировкалау проекты һәм межалау проекты нигезендә 16:37:180401:6 кадастр номерлы җир кишәрлегенә һәм алына торган җир кишәрлегенә карата кадастр эшләрен үткәрүне тәэмин итәргә.

5. Бу карарның үтәлешен тикшерүдә тотуны Татарстан Республикасы Җир һәм мөлкәт мөнәсәбәтләре министрлыгына йөкләргә.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин